
| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |  | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 декабрь 2024 ел. № 11

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Смәел авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Балтач районы прокуратурасының 14.11.2024 № 02-08-01-2024/Прдп444-24-20920011 протестын карап һәм "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 04.08.2023 № 480-ФЗ Федераль закон нигезендә Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгы районның:

1. Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге башлыгының 23.11.2015 ел, № 27 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Смәел авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлек 1.2 пунктында "электрон хәбәрләр рәвешендә" сүзләреннән соң "электрон документ рәвешендә, шул исәптән "дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы" (алга таба - Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып" сүзләрен алмаштырырга,”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Смәел авыл җирлеге башлыгы: Р.Г.Йосыпов